Проект
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль район Советы
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Балтач районы Ямбурово поселогын бетерергә.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керә торган «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Норма авыл җирлеге», «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**3 статья**

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 январендагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 8 (III өлеш); 2012, № 9, 2014, №12 (VII өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2026, №1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


1) 3 статьяның алтынчы абзацында «, Ямбурово поселогы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре

**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 17 (13) - 1 (Б) | - Марий Эл Республикасы |
| 1 (Б) - 25 (14) | - Киров өлкәсе |
| 25 (14) - 38 (51) | - Кукмара муниципаль районы |
| 38 (51) - 37 (50) | - Саба муниципаль районы |
| 37 (50) - 17 (13) | - Арча муниципаль районы |

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта – схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балтач шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Борбаш авыл җирлеге |
| 3 | Борнак авыл җирлеге |
| 4 | Югары Субаш авыл җирлеге |
| 5 | Карадуган авыл җирлеге |
| 6 | Куныр авыл җирлеге |
| 7 | Кече Лызи авыл җирлеге |
| 8 | Норма авыл җирлеге |
| 9 | Нөнәгәр авыл җирлеге |
| 10 | Пыжмара авыл җирлеге |
| 11 | Салавыч авыл җирлеге |
| 12 | Смәел авыл җирлеге |
| 13 | Сосна авыл җирлеге |
| 14 | Урта Көшкәт авыл җирлеге |
| 15 | Чепья авыл җирлеге |
| 16 | Шеңшеңәр авыл җирлеге |
| 17 | Шубан авыл җирлеге |
| 18 | Яңгул авыл җирлеге |

»;

3) 2 нче кушымтада:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдәге чиге Балтач, Арча муниципаль районнары һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Сосна Пүчинкәсе авылыннан 5,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 17 нче (13 нче) тоташу ноктасыннан алып, Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Шода авылыннан 6,8 км көньяк-көнбатышта урман кырыенда урнашкан Татарстан Республикасы, Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан 1 нче (Б) тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Киров өлкәсе белән чиктәш җирдәге чиге 1 нче (Б) тоташу ноктасыннан алып, Татарстан Республикасының административ чиге буйлап Балтач, Кукмара муниципаль районнары һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында, Алан авылыннан 8,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче(14 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) дүртенче – алтынчы абзацларны туры килү буенча бишенче – җиденче абзацлар дип санарга;

4) 3 нче кушымтада:

а) өченче абзацта «әлеге елгада 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр» сүзләрен, «аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 400 м, көнчыгышка таба 1,7 км да урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Сосна авыл җирлеге белән чиктәш җирдәге чиге 30 нчы тоташу ноктасыннан Зур Лызи 2 өлеш авылына таба автомобиль юлының көньяк ягы буйлап көнчыгышка таба 1,6 км, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км Балтач - Әтнә автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап Шушма елгасының уртасына кадәр, аннары 2,4 км Шушма елгасы агымы буенча аска таба Түбән Сосна авылыннан 1,3 км көньяк – көнчыгышка таба «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», Норма һәм Сосна авыл җирлекләренең чикләре кисешкән урында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр»;

в) бишенче абзацта «авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, Балтач - Шәмәрдән автомобиль юлының бүлү полосасын кисеп үтеп көньякка таба 100 м, аннары көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының бүлү полосасының көньяк чиге буйлап 550 м бара, шуннан соң» сүзләрен «көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап 300 м, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 350 м, сынык сызык ясап, көньякка таба 300 м, көнбатышка таба 200 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 150 м, урман полосасын кисеп үтеп көнбатышка таба 180 м, шуннан соң сынык сызык ясап, көньякка таба 170 м, аннары көнчыгышка таба Балтач - Шәмәрдән автомобиль юлының бүлү полосасының төньяк чиге буйлап 550 м бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлын кисеп үтә һәм» сүзләренә, «төньяк-көнбатыш буйлап 150 м» сүзләрен «көньяк-көнчыгыш буйлап 150 м» сүзләренә алмаштырырга»;

5) 8 нче кушымтада 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Куныр авыл җирлегенең Киров өлкәсе белән кисешкән җирдәге чиге Татарстан Республикасы, Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан, Шода авылыннан 6,8 км көньяк-көнбатышка таба урман кырыенда урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан Татарстан Республикасының административ чиге буйлап Куныр, Пыжмара авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан, Иске Пукшинер авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышка таба урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

6) 10 нчы кушымтаның тугызынчы абзацында «авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк - көнбатышка таба, Балтач-Шәмәрдән автомобиль юлының бүлү полосасын кисеп үтеп, 100 м көньякка таба, аннары шушы

автомобиль юлының бүлү полосасының көньяк чиге буйлап 550 м көнчыгышка таба бара, аннары» сүзләрен «көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап 300 м, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 350 м, сынык сызык ясап, көньякка таба 300 м, көнбатышка таба 200 м, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 150 м, урман полосасын кисеп үтеп, көнбатышка таба 180 м, аннары, сынык сызык ясап, көньякка таба 170 м, аннары көнчыгышка таба Балтач - Шәмәрдән автомобиль юлының бүлү полосасының төньяк чиге буйлап 550 м, аннары әлеге автомобиль юлын кисеп үтә һәм» сүзләренә, «150 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап» сүзләрен «150 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап» сүзләренә алмаштырырга;

7) 11 нче кушымтадагы сигезенче, тугызынчы, унынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

8) 12 нче кушымтадагы алтынчы, җиденче, сигезенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

9) 14 нче кушымтада:

а) бишенче абзацта «600 м да» сүзләрен «1 км да» сүзләренә алмаштырырга.;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Смәел авыл җирлегенең Шеңшеңәр авыл җирлеге белән чиктәш урындагы чиге 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча өскә таба 3,3 км, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасының уң ярына кадәр 1,5 км һәм аның агымы буенча өскә таба 3,4 км, Арбор - Шеңшеңәр автомобиль юлының бүлү полосасын кисеп үтеп, Шушма елгасы буенда Смәел авылыннан 1 км көньяк-көнбатышта Смәел, Шеңшеңәр һәм Борнак авыл җирлекләре чикләре тоташкан җирдә урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

10) 15 нче кушымтада:

а) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сосна авыл җирлегенең «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдәге чиге Сосна авыл җирлеге, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Шубан авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Зур Лызи 2 өлеш авылыннан 1,6 км көнчыгышка таба урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан, Зур Лызи - 2 өлеш авылына автомобиль юлының көньяк ягы буйлап көнчыгышка таба 1,6 км, аннары Балтач - Әтнә автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап Шушма елгасының уртасына кадәр көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, шуннан соң Шушма елгасы агымы буенча аска таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр 2,4 км бара.»;

б) тугызынчы абзацта «төньяк-көнчыгышка таба Шушма елгасы буйлап аның сул ярына кадәр 10 м, төньякка таба сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, аннары бара» сүзләрен төшереп калдырырга.;

11) 18 нче кушымтаның дүртенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Шеңшеңәр авыл җирлегенең Смәел авыл җирлеге белән чиктәш җирдәге чиге Шеңшеңәр, Смәел авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Шеңшеңәр авылыннан 1,0 км төньякка таба Шушма елгасында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча өскә таба 3,3 км, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасының уң ярына кадәр 1,5 км һәм аның агымы буенча 3,4 км өскә таба Арбор – Шеңшеңәр автомобиль юлының бүлү полосасын кисеп үтеп, 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

12) 19 нчы кушымтада:

а) өченче абзацта «Шушма елгасында көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км» сүзләрен «көнчыгышка таба 1,7 км» сүзләренә алмаштырырга, «төньяк-көнчыгышка таба 10 м Шушма елгасы буйлап аның сул ярына кадәр, төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап 450 м, аннары бара» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта «Шушма елгасының 1,2 км» сүзләрен «Шушма елгасының 1,2 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 400 м» сүзләренә алмаштырырга»;


**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
(Рәисе)

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган
**карта-схемасы**

«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово
поселокны бетерү турында һәм аерым муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү
һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта



**«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проекты Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма һәм Сосна авыл җирлекләренең чиктәш чикләрен үзгәртү максатында әзерләнде.

Балтач муниципаль районында барлык торак пунктларга аларның яшәеше һәм үсеше буенча анализ ясалды.

Анализ нәтиҗәләре буенча үсеш критерийларына туры килми торган бер торак пункт ачыкланды - Куныр авыл җирлеге составындагы Ямбурово поселогы.

Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге составына 8 торак пункт керә һәм анда яшәүчеләр түбәндәгечә: Куныр авылы - 682, Кургем авылы - 61, Шода авылы - 254, Дорга авылы - 265, Курамьял авылы - 39, Кускем авылы - 49, Улисьял авылы - 268, Ямбурово поселогы - 0.

2002 – 2006 елларда авыл администрациясе тарафыннан тутырылган 12 номерлы хуҗалык кенәгәсе нигезендә 1 йорт хуҗалыгы алып барылуы турында язып куелган.

Куныр авыл җирлегенең 2006 елдан бүгенге көнгә кадәр тутырылган хуҗалык кенәгәләрендә Ямбурово поселогында йорт хуҗалыклары алып бару турында яңа язмалар юк.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, торак пунктта теркәлгән кешеләр юк.

Соңгы кеше 2004 елның 28 декабрендә Балтач муниципаль районының Чепья авылына күченгән.

Ямбурово поселогының фаразланган торак пункты урынында, кадастр карталары нигезендә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә керә торган, авыл хуҗалыгын алып бару өчен рөхсәт ителгән кадастр номеры 16:12:051005:29 булган җир кишәрлеге урнашкан. Бу территориядә торак пункт җирләре юк.

Үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителеш, су агызу, газ белән тәэмин ителеш, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле әһәмияттәге юллар категориясенә кертелгән юллар булмавы ачыкланды. Торак

пункт территориясендә социаль объектлар, мәдәни мирас объектлары һәм истәлекле урыннар да юк.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Ямбурово поселогының торак пункт билгеләрен югалтуын, асылда эшләмәвен һәм киләчәктә үсеш перспективалары булмавын билгеләп үтәргә кирәк.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлегендә яшәүчеләр торак пунктны бетерү инициативасын хуплады, законда каралган процедуралар үтәлде.

2036 елга кадәрге фараз белән 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең пространстволы үсеш стратегиясе нигезендә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 декабрендәге 4146-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган) Россиянең халыкны күчерү, инфраструктура һәм икътисад системаларын һәм аларга якын территорияләрнең үсешен тәэмин итә торган терәк торак пунктлар системасын булдыру төп пространстволы өстенлек булып тора.

Бүгенге көндә терәк торак пунктларны үстерү милли максатларга ирешүгә һәм милли иминлекне тәэмин итүгә ярдәм итә.

Әлеге фактны исәпкә алып, чикләрнең «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен арттыру ягына үзгәрүе актуаль, бу районга туризм, инвестицияләр җәлеп итүчәнлек, җәмәгать пространстволары өлкәсендә үсеш, шулай ук дәүләт республика программалары кысаларында терәк торак пунктларны өстенлекле финанслау мөмкинлеге бирә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының терәк торак пунктлары һәм аларга якын территорияләр исемлеген раслау турында» 2023 елның 22 февралендәге 474-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге терәк торак пунктлар исемлегенә кертелде.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Норма авыл җирлеге», «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрендә гавами тыңлаулар уздырылды. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр чикләрне үзгәртү инициативасын хупладылар. Күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул ителде. Димәк, законнарда каралган процедуралар үтәлгән.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы тарафыннан  Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә чикләрнең урнашу урынын рәсми билгеләүгә бәйле рәвештә закон проектында шулай ук «Балтач муниципаль районы», «Куныр авыл җирлеге», «Смәел авыл җирлеге», «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең Киров өлкәсе чиге белән тоташкан урыннарда чик өлешләренең график һәм картографик (текст) тасвирламасын төгәлләштерү карала, шулай ук «Нөнәгәр авыл җирлеге» һәм «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренә – Татарстан Республикасы территориясе составына керми торган басу аша кишәрлекләренең тасвирламаларын төшереп калдыру өлешендә (Татарстан

Республикасы Дәүләт Советының 2023 елның 13 июлендәге 2040-VI ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы һәм Киров өлкәсе арасындагы чикнең урнашу урынын билгеләү турында Татарстан Республикасы һәм Киров өлкәсе арасында 2023 елның 2 июлендәге 30/177/01/2023 номерлы килешү). Аныклаулар техник характер йөртә.

Закон проекты нигезендә 2, 3, 8, 10, 11, 12, 14, 15, 18, 19 кушымтага үзгәрешләр кертү, шулай ук «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итү тәкъдим ителә.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.

**«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘМӘ**

«Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.